# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Олыяз авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2025 елның 28 ноябре № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 33-ФЗ Федераль “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы , Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Олыяз авылы торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Олыяз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертергә, моңа 1 төркем инвалидлар, көндезге формада укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәр бала тәрбияләүче ялгыз аналар, 80 яшькә җиткән һәм өлкәнрәк; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срочная хәрби хезмәткә чакырылган затлар; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларны һәм аларның гаилә әгъзалары керми.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

1) су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

2) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

3) яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту; янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

4) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

5) тротуарларны төзү, ремонтлау;

6) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау;

7) каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

8) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерүме?

3. Элеге карарны Олыяз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы Муниципаль

берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче

Олыяз авыл жирлеге башлыгы Р. Ф. Маликов